ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү турында

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы, Совет рәисе И.М. Кәшшафов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе С.М. Захарова, профессор, тарих фәннәре докторы, Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирас югары мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме кафедрасы мөдире Р.Р. Фәхретдинов, Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Е.И. Согрина мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Патриотик тәрбия дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, граждан җәмгыяте институтларының һәм гаиләнең гражданнарда югары патриотик аң, үз Ватанына тугрылык хисе, граждан бурычын һәм Ватан мәнфәгатьләрен яклау буенча конституциячел бурычларны үтәүгә әзерлек булдыру буенча системалы һәм максатчан эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Үсеп килүче буынны патриотик тәрбияләү өлкәсендәге эшчәнлек Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә таяна һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Республикада «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләрне патриотик тәрбияләү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла, аның кысаларында патриотик тәрбия системасын модернизацияләү һәм граждан үзаңы булдыру, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә гомумроссия гражданлык бердәйлеген ныгыту, граждан җаваплылыгын, Россия тарихы өчен горурлык хисен булдыру чаралары, гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруга кадәр әзерләү

чаралары, патриотик тәрбия өлкәсендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин итү чаралары башкарыла.

Төп патриотик тәрбия юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

граждан-патриотик юнәлеш – балаларда һәм яшьләрдә патриотик аңны, Россия гражданының һәм патриотының кыйммәтләрен һәм үз-үзен тоту нормаларын, реаль тормышның социаль әһәмиятле процесслары һәм күренешләре турындагы белемнәрне булдыру, шулай ук көндәлек эшчәнлектә аларны куллану сәләтен үстерү максатларында;

мәдәни-патриотик юнәлеш – олы һәм кече Ватан, үз халкы мәдәнияте һәм милли традицияләре турында тарихи хәтерне саклау, үсеп килүче буында илнең күренекле эшлеклеләре, истәлекле даталар һәм вакыйгалар хакында белемнәр булдыру максатларында;

хәрби-патриотик юнәлеш һәм яшьләрне хәрби хезмәткә чакыруга кадәр әзерләү – яшьләрдә граждан бурычын һәм Ватанны саклау буенча конституциячел бурычларны үтәүгә уңай мотивация булдыру максатларында;

спорт-патриотик юнәлеш – физик культура һәм спорт белән шөгыльләнгәндә мораль сыйфатларны, ихтыяр көче сыйфатларын үстерү, чыдамлылыкны, ныклыкны, батырлыкны, тәртиплелекне тәрбияләү, Ватанга хезмәт итү һәм Ватанны саклауга әзерлек тәҗрибәсен булдыру максатларында.

Балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү системасын ныгыту һәм үстерү буенча күреләә торган чаралар дәүләт сәясәте максатларын һәм бурычларын, үсеп килүче буынның заманча психологиясен исәпкә алып камилләштерелә.

Патриотик тәрбия системасында гомуми белем бирү оешмалары һәм кадет мәктәпләре, «ЮНАРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик хәрәкәте һәм «Беренчеләр Хәрәкәте» балаларның һәм яшьләрнең гомумроссия иҗтимагый-дәүләти хәрәкәте эшчәнлеге мөһим роль уйный.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы, Совет рәисе И.М. Кәшшафов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе С.М. Захарова, профессор, тарих фәннәре докторы, Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирас югары мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме кафедрасы мөдире Р.Р. Фәхретдинов, Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Е.И. Согрина мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты белән берлектә балаларның һәм яшьләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, аларны патриотик тәрбияләүне җайга салучы законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп торуны дәвам итәргә.

3. «Татарстан Республикасында гражданнарны патриотик тәрбияләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләү буенча эшче төркем җитәкчесе А.Р. Зариповка закон проектын алга таба Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен аның буенча тәкъдимнәрне үз вакытында бирүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Гражданнарда Ватан тарихына карата хөрмәт, үз халкы, аның казанышлары өчен горурлык, милли традицияләргә, изге урыннарга һәм символларга карата хөрмәт тәрбияләү, балаларда һәм яшьләрдә Ватанны саклау буенча конституциячел бурычны үтәү кирәклеген аңлауны, хәрби традицияләрне саклауга һәм арттыруга мотивацияне булдыру максатларында республика башкарма хакимият органнарының патриотик тәрбия өлкәсендәге эшен активлаштырырга.

4.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләрне патриотик тәрбияләү» ярдәмче программасына, балаларда һәм яшьләрдә граждан-патриотик аңны үстерү максатларында аларны даими патриотик тәрбияләү системасын булдыру максатчанлыгын исәпкә алып, патриотик тәрбияләү юнәлешләрен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карарга.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына үз карамагындагы мәсьәләләр буенча түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Авыр тормыш хәлендәге яшүсмерләр, яшьләр субкультураларында катнашучылар, урам яшьләре белән эшләүгә аерым игътибар биреп, балаларда һәм яшьләрдә аңлы патриотизмны булдыру максатларында алар белән эшне көчәйтергә.

5.2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү оешмаларында, балалар сәламәтләндерү лагерьларында балаларны патриотик тәрбияләү эшен, шул исәптән тарихи даталарга һәм вакыйгаларга, бәйрәм көннәренә һәм вакыйгаларына багышланган тематик чараларны оештыру һәм үткәрү аша, көчәйтергә.

5.3. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга мәдәни-тарихи аң-белем тарату, аларны рухи үстерү һәм аларда патриотик аң булдыру максатларында алар белән сыйныфтан тыш эшләү мәсьәләсен карарга.

5.4. Иҗтимагый оешмалар, бергәлекләр һәм хәрәкәтләр белән берлектә яшь гражданнарны патриотик юнәлештәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә җәлеп итәргә.

5.5. Профильле оешмаларның рәсми интернет сайтларында, башка мәгълүмат ресурсларында, мәгариф оешмалары биналарындагы мәгълүмат стендларында патриотик юнәлештәге мәгълүматны урнаштыру һәм актуальләштерү эшен дәвам итәргә.

5.6. Балаларны һәм яшьләрне «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүгә әзерләү өчен шартлар тудыру максатларында спорт-патриотик тәрбия системасын үстерүне дәвам итәргә.

6. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына яшьләр мохитендә экстремистлык күренешләренә каршы тору эшен көчәйтергә тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

7.1. Яшүсмерләр клублары эшчәнлеге кысаларында патриотик тәрбия эшен оештырырга.

7.2. Яшьләрдә Ватанны саклауга һәм хәрби хезмәткә мотивацияне үстерү һәм әзерлекне тәрбияләү максатларында хәрби-патриотик клублар булдыру һәм аларның ветераннар оешмалары белән хезмәттәшлеген оештыру мөмкинлеген карарга.

7.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә балаларның һәм яшьләрнең аңына тискәре йогынтысы булган мәгълүмат һәм сайтлар ачыкланганда, алар турында мәгълүматны мондый мәгълүматтан һәм мәгълүмат ресурсларыннан файдалана алуны чикләү чараларын күрү өчен оператив рәвештә вәкаләтле дәүләт органнарына җибәрергә.

8. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

8.1. Массакүләм мәгълүмат чараларында патриотик юнәлештәге материалларны урнаштыруга аерым игътибар бирергә.

8.2. Гражданнарны патриотик тәрбияләү максатларында үткәрелә торган чараларны тулысынча яктыртуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясенә эшче яшьләрне патриотик тәрбияләү һәм алар тарафыннан «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәү өчен шартлар тудыру эшен активлаштыруны тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советына тәрбия эше программалары кысаларында югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучыларны патриотик тәрбияләү мәсьәләләренә аерым игътибар бирүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 июне
№ 2025-VI ДС